Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Горкино торак пунктында гражданнар җыены карары

2024 елның 23 ноябре № 4

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Горкино торак пунктында 2025 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (29.11.2023 №1532 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Горкино Чыршылы торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2025 елда Лениногорск муниципаль районы Яңа Чыршылы авыл җирлегенең Горкино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2025 елда 2500 (Ике мең биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Горкино т. п. территориясендә үлән чабу; Горкино т. п. Үзәк урамындагы карт агачларны кисү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Горкино торак пунктында үзәк урам буенча грунт-вак таш юлларны ремонтлау)

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Яңа Чыршылы поселогы үзидарә администрациясе бинасында Заречная ур., 25, авыл мәдәният йорты бинасында Үзәк урам 12А йорт, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Яңа Чыршылы авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә.Мөхәмәтшина